**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «17» декабреннән № 311

## 2025 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының торак фондында торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләмен билгеләү турында

Россия Федерациясенең 2006 елның 13 нче августындагы «Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йорттагы гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча тиешле сыйфатта булмаган һәм (яки) билгеләнгән вакыттан узып киткән өзеклекләр белән хезмәт күрсәткән очракта торак урынны карап тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында»гы 491 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма коомитеты карар бирә:

1. Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы фатир хуҗаларына торак урыннарны карап тоткан өчен 2025 елга хезмәтләр төрләре буенча түләү күләмен кушымта нигезендә билгеләргә һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан гамәлгә кертергә (кушымта).

2. Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын

сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы фатир хуҗаларына күпфатирлы йортта гомуми милектән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләменә кергә торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләме, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йорт белән идарә итүче оешма тарафыннан билгеләнә дип билгеләргә.

3. Күпфатирлы йортта торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме күрсәтелә торган хезмәтләрнең составына, күпфатирлы йортның конструктив һәм техник үзенчәлекләренә карап исәпләнә һәм үзгәрә дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2024 елга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында торак хезмәтләренә тарифларны раслау турында» 2023 елның 20 декабрендәге 278 номерлы карарын (2024 елның 07 ноябрендәге 271 номерлы карардагы үзгәрешләр белән) 2025 елның 01 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарны кушымтасы белән«Яңа Чишмә хәбәрләре» район газетасында бастырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (икътисад буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «17» декабреннән
311 номерлы карарына
кушымта

Дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре һәм наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучыларны, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яисә) гомуми җыелышта 2025 елга торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак урыннар милекчеләрен карап тоткан өчен түләү күләме

| № т/б | Түләүнең исеме | Хезмәт күрсәтүне үлчәү берәмлеге | Хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен тариф (1 сум). | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 01.01.2025 тән 30.06.2025 кә кадәр | 01.07.2025 тән 31.12.2025 кә кадәр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 3,71 | 4,42 |
| 2 | Күпфатирлы йортның гомуми мөлкәте составына керә торган гомуми файдаланудагы урыннарны карап тоту, шул исәптән: | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | | |
| 2.1 | - йорт эчендәге гомуми файдаланудагы урыннарны җыештыру; | | 6,93 | 9,29 |
| 2.2 | - йорт яны территориясен җыештыру; | | 3,90 | 3,99 |
| 2.3 | - дератизация (дезинсекция); | | 0,17 | 0,17 |
| 3 | Бинаның төзелеш корылмаларына, инженерлык системаларына һәм башка гомумйорт милкенә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, шул исәптән: | аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | | |
| 3.1 | - торак бинаны; | | 10,18 | 11,36 |
| 3.2 | - йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын; | | 3,27 | 4,47 |
| 3.3 | - йорт эчендәге электр белән тәэмин итү һәм электр җиһазлары челтәрләрен; | | 0,4 | 0,54 |
| 3.4 | - күпфатирлы йортларда йорт эчендәге газ җиһазлары системаларын; | | 0,31 | 0,35 |
| 3.5 | - күпфатирлы йортларның вентиляция һәм төтен каналларын тикшерү (карау) һәм чистарту: | | 0,79 | 0,79 |
| 3.6 | - күпфатирлы йортларда мичләрне, каминнарны һәм учакларны (төтенлекләрне) тиешле тәртиптә тоту максатларында башкарыла торган эшләр | | 1,19 | 1,25 |
| 4. | Эчтәге газ җиһазларын техник диагностикалау (түләүне исәпләү диагностикалауны үткәрү вакыты башланганчы 12 ай эчендә башкарыла) | кв. м. аена торак бинаның гомуми мәйданы кв. м. | 1,00 | 1,00 |